**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9а

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**26 март 2021 ел** **№ 8**

**Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү тәртибен раслау турында**

2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә, Биектау районы прокурорының 2021 елның 27 гыйварындагы 02-08-03 номерлы күрсәтмәсен карап, һәм кергән мөрәҗәгатьләрне анализлауның бердәм тәртибен билгеләү максатларында, Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализ үткәрү Тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Суыксу авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Низамиев

Кушымта
Расланган
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы №8 карары белән

**Гражданнарның җирле үзидарә органнарына кергән мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү**
**ТӘРТИБЕ**

1. Әлеге Тәртип 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Башлыгына һәм Башкарма комитетына (алга таба - җирле үзидарә органнары) кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ гражданнар мөрәҗәгатьләре керүгә, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау эшенең сыйфатын күтәрүгә, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнүгә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын арттыру максатларында уздырыла.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализ елга 1 тапкыр үткәрелә.

4. Җирле үзидарә органнарына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләрен үткәрелгән гомумиләштерү һәм анализлау нәтиҗәләре буенча вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан хисап чорында җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау турында хисап рәсмиләштерелә (алга таба - Хисап).

5. Хисапта түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- кергән, кабат адресланган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең, электрон документ рәвешендәге мөрәҗәгатьләрнең саны турында мәгълүмат;
- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;
- шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны турында;
- гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;
- мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар турында (булган очракта).

6. Җирле үзидарә органнарына кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында теркәлгән “Электрон Хөкүмәт” телефоны буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон

документлар әйләнеше ведомствоара системасында теркәлгән “кайнар линия” телефоны буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына язма рәвештә, Интернет кабул итү яисә электрон почта аша җибәрелгән электрон хәбәрләрне исәпкә алып, Суыксу авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

7. Хисап «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының авыл җирлекләре бүлегендә хисап чорыннан соң килә торган айның 15 числосына кадәр срокта урнаштырыла.